| СОВЕТ НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 08.10.2015 | с. Набережные Моркваши | № 2-17 |

«Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җир салымы билгеләү турында» 2005 елның 17 ноябрендәге 13 номерлы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районының
Яр буе Морквашы авыл җирлеге советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2005 нче елның 17 нче ноябрендә кабул ителгән 13 нче номерлы «Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 6 статьяның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир салымын җирле бюджеттан финанслана торган бюджет учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләренә карата киметелгән салым ставкасин 0,6 %ка куллану рәвешендә ташлама бирергә, моңа әлеге Карарның 2 статьясындагы 1, 2, 3, 4 пунктларында каралган җир кишәрлекләре керми.

1.2 Карарның 6 статьясын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Бюджет учреждениеләре тарафыннан республика һәм федераль бюджетлардан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата салымның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә 1 %ка ташлама бирергә, моңа әлеге Карарның 2 статьясындагы 1, 2, 3, 4 пунктларында каралган җир кишәрлекләре керми.

2. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» карары текстын яңа редакциядә расларга (1нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваш авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов

1 нче кушымта
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Советының 2015 елның
08 октябрендәге 2-17 карарына

Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориядә җир салымын билгеләү турында

Статья 1. Гомуми нигезләмәләр.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлеге нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

Статья 2. Салым ставкалары.

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 %;

2. торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә карата 0,3 %;

шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата

3. Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;

4. Башка җир кишәрлекләренә карата 1.5 %.

3 статья. Хисап чоры.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

4 статья. Салым түләү тәртибе һәм сроклары.

Салым түләүче оешмаларга салым түләү 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарылачак. Беренче квартал узу белән 15 майдан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше, икенче квартал үткәч, 15 августтан да соңга калмыйча, өченче квартал үткәч, 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча.

Салым чоры нәтиҗәләре буенча салым түләүче оешмалар тарафыннан түләнергә тиешле салым 15 февральдән дә соңга калмыйча, үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

5 статья. Салым түләүчеләр тарафыннан салым салу базасын киметү хокукын раслый торган документларны тапшыру тәртибе һәм сроклары.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезендә салым

базасын киметү хокукын раслаучы документлар салым салу объекты дип танылган җир участогы урнашкан урын буенча салым органына тапшырыла:

- шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затлар - салым чоры булган елның 31 декабренә кадәр срокта.

Салым базасын киметүгә хокук барлыкка килгән (туктатылган) очракта, салым түләүчеләр әлеге хокукның барлыкка килүен (туктатылуын) раслаучы документлар, ул барлыкка килгәннән соң 30 көн эчендә.

6 статья. Салым ташламалары

Салым салудан азат итергә:

1. Муниципаль берәмлек башкарма хакимияте органнары, зиратлар һәм гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата;

2. Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм инвалидларның тол хатыннары, Бөек Ватан сугышы инвалидларының тол хатыннары;

3. Муниципаль берәмлекнең башкарма хакимияте органнары авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә карата, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары биләгән җир кишәрлекләренә, мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, истәлекләр, бәйрәм чараларын уздыру урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән җир кишәрлекләренә карата.

Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләренә карата салымның кимателгән ставкасын 0,6% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташламаны, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, бирергә.

Гомуми файдаланудагы 1-3 категориядәге автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата салым түләүгә салым 0,05 %ның кимателгән ставкасын куллану рәвешендә ташлама бирергә.

Бюджет учреждениеләре тарафыннан республика һәм федераль бюджетлардан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, салымның кимателгән ставкасын 1% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташлама бирергә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Моркваше авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов